ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 119 "03" 03 2025 ел

2025 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында Карар кабул итү өчен гражданнар кеременең һәм мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган кеременең һәм милектәге мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы нигезендә гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан һәм салым салынырга тиешле, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтада бәян ителгән 2025 елның 27 гыйнварындагы 30 номерлы хатында «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» коммерциягә карамаган партнерлыгы, шулай ук «Торак урын мәйданының исәпкә алу нормасы һәм социаль наем шартнамәсе буенча Торак урын мәйданын бирү нормасы турында «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 12 маендагы 307 номерлы карары белән расланган Торак урын мәйданының исәпкә алу нормасын үзгәртү хакында» Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 01 октябрендәге 630 номерлы карары нигезендә, Спас муниципаль районы комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында Карар кабул итү өчен минималь чик күрсәткечләрне расларга:

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының һәр гаилә әгъзасына социаль наем буенча Торак урын бирү нормасы буенча торак урынның базар хакының исәп-хисап күрсәткеченә тигез булган чиге 900 414 сум күләмендә.

1.2. һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең күрсәткеч чиге 17 122,8 сум күләмендә.

2. Спас муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм ТКХ бүлегенә, Спас муниципаль районы Болгар шәһәр Башкарма комитетына әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрне торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә куелганда файдаланырга.

3. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru халыкка җиткерергә

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Спас муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе В.А. Осокин